**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

КАРАР

№ 246 19.03.2020 ел.

Аксубай муниципаль районы Советының «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турындагы нигезләмә хакында" 20.12.2012 елның кабул ителгән 139 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 16.12.2019 елдагы 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 25.12.2008 елдагы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елның 25-ФЗ номерлы федераль закон, Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендә, Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Аксубай муниципаль районының «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында"гы 20.12.2012 елның 139 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлегендәге 1.3 пунктын «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, әлеге Нигезләмәдә бәян ителгән тәртипне исәпкә алып, муниципаль хезмәт турындагы законнарга каршы килми торган өлешендә, хезмәт законнары белән билгеләнә» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлек, ялында булу

чорларын санамыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми".

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http: //Aksubaevo. tatarstan. ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http: // pravo. tatarstan. ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе: К. К. Гилманов